Республика Татарстан
Совет Альметьевского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге советы

РЕШЕНИЕ
КАРАР

2017 ел, 23 март
№ 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы " Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлегендә 2007 елның 27 июлендәге 11 номерлы карары белән расланган ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Әлмәт авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча ачык тыңлауларны оештыручы - комиссия;

- ачык тыңлаулар үткәрү вакыты-2017 елның 24 апрелендә 14 сәгать;

үткәрү урыны: Татарстан Республикасы, Әлмәт авылы, Ленин урамы, 56А нчы йорт, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты;

3. Фикер алышына торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Татарстан Республикасы, Әлмәт авылы, Ленин урамы , 56А нчы йорт, Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты (эш көннәрендә 7.00 дән 16.30 сәгатькә кадәр (төшке аш 11.30 дан 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Әлмәт авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссия:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы « Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәргә;;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә 2017 елның 24 апреленнән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга;

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проектны Сарман муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://sarmanovo.tatarstan.ru/ -.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Әлмәт авыл җирлеге
Советы Рәисе — Д.Ә. Газизов.